УДК 811.512.145

*Р.Ф. Мирхәев*

# XIX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ – XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНДӘ ҖӨМЛӘЛӘРНЕҢ СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена изучению стилистических особенностей употребления предложений в татарском литературном языке второй половины XIX – начала XX века. Они, как и другие языковые единицы, играют важную роль в формировании выразительности и стилистической окраски текста, а также в достижении определенного эмоционального фона. Актуальность работы определяется недостаточной разработкой в татарском языкознании проблемы их исследования в диахроническом аспекте. Несмотря на то, что синтаксическая структура татарского языка указанного периода в той или иной степени рассматривается в грамматиках и учебниках татарского языка, составленных в то время, в татарском языкознании она до настоящего времени не становилась объектом исследований исторической направленности.

В целом, как показало исследование, в татарском литературном языке второй половины XIX – начала XX века на предложения накладываются такие стилистические задачи, как описание персонажей, раскрытие их внутреннего мира и психологического состояния, формирование пейзажных картин, оценка социальных явлений и общественных институтов, доведение до читателя информации этнографического, социально-экономического, конфессионального, географического и исторического характера, построение фабулы, ведение повествования и т. д.

**Ключевые слова:** татарский литературный язык, синтаксис, стилистика, предложения, стилистические функции синтаксических единиц

The article is devoted to the study of stylistic features of the use of sentences in the Tatar literary language of the second half of the 19th – early 20th century. They, like other linguistic units, play an important role in shaping the expressiveness and stylistic coloring of the text, as well as in achieving a certain emotional background. The relevance of the work is determined by the insufficient development in Tatar linguistics of the problem of their research in the diachronic aspect. Despite the fact that the syntactic structure of the Tatar language of this period is more or less considered in grammars and textbooks of the Tatar language compiled at that time, it has not yet become the object of historical research in Tatar linguistics.

In general, the study showed that in the Tatar literary language of the second half of the 19th – early 20th century, sentences are superimposed with such stylistic tasks as describing characters, revealing their inner world and psychological state, forming landscape paintings, evaluating social phenomena and public institutions, and informing the reader of ethnographic, socio-economic, confessional, geographical and historical in nature, plotting, storytelling, etc.

**Keywords:** Tatar literary language, syntax, stylistics, sentences, stylistic functions of syntactic units

Хәзерге татар тел белемендә *җөмлә* термины фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итеп, сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торган иң кыска сөйләм берәмлегенә карата кулланыла. Аның төп үзенчәлекләре буларак хәбәрлек (сөйләүченең нәрсә турында булса да хәбәр итүе) һәм модальлек (сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, сөйләмгә мөнәсәбәт белдерүе) аерып чыгарыла [6: 15]. Беренче үзенчәлек нигезендә җөмләләр гади (бер хәбәрлекле) һәм катлаулы (берничә хәбәрлекле) төрләргә бүленәләр [7: 54].

**Гади җөмләләрнең стилистик кулланылышы.** Стилистик планда башка синтаксик берәмлекләр кебек гади җөмләләр дә төрле үзенчәлекләргә ия булулары белән характерланалар. Мәсәлән, сөйләмдә гадилеккә һәм җыйнаклыкка ирешү максатында аларның җыйнак төрләренә мөрәҗәгать итәләр. Җәенке гади җөмләләр исә сәнгатьчә тасвирлыкка ирешү, катлаулы күренешләрне һәм категорияләрне ачып бирү чарасы булып торалар. Ә инде автор яисә персонажлар тарафыннан тасвирлана торган вакыйгаларга һәм күренешләргә белдерелгән мөнәсәбәт хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләр тарафыннан чагылдырыла. Моннан тыш сөйләмдә билгеле бер максатларда, аерым алганда, сүзләрне тавтологик кабатлаулардан котылу өчен, аларның бер һәм ике составлы, ким һәм тулы төрләре җәлеп ителә. Гади җөмләләргә хас стилистик үзенчәлекләр билгеле бер дәрәҗә XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы татар поэзиясе һәм мәгърифәтчелек әсәрләре телендә дә чагылыш таба. Мәсәлән, шигырьләрдә гади хикәя җөмләләр катлаулы градацияләр тудыру өчен җәлеп ителәләр:

***Каты эссе. Һава бөрку.*** *Кыза дөнья, сабыр җитми,*
***Җил исми аз гына да, бер генә яфракны селкетми*** [9: 124].

Мәгърифәтче язучылар тарафыннан әлеге синтаксик берәмлекләр беренче чиратта фабула кору өчен файдаланылалар. Бу гади хикәя җөмләләрнең әсәрләрдә тасвирлана торган вакыйгаларга фон булып хезмәт иткән процессларны белдереп килүендә чагылыш таба: *Бикбулат менла түрдә утырмыш. Соңра шәкердләре йирле йиренҗә йәрләшмешләр* [1: 15]; *Көнләр гадәтчә кичейурлар. Муса әфәнденең хәлене белергә һәр көн килейурлар* [2: 35]; *Шимди Накәс мулла вә углы Габделгафур, ике мөсафир вә мәзин биш кемсәнә мулла ивендә чәй эчейурлар* [3: 3].

Моннан тыш алар тасвирланачак вакыйгаларга кереш буларак хезмәт иткән эш-хәрәкәтләрне атап киләләр: *Сабах сәгать унда Казан мөсафирханәләрендә бер олуг вә могтәбәр мөсафирханә йанына күб адәмләр җәмгъ улмышлар* [2: 4]; *Әкъръбе вә карендәшләре Габделгафурны мәдрәсәйә озатмайа килмешләр* [3: 3].

Шуның белән бергә текстларда гади хикәя җөмләләр язучылар тарафыннан әсәрләрдә тасвирлана торган вакыйгалар белән тыгыз бәйләнештә булган процесслар турында сүз барганда кулланылалар: *Икенче көнне мәкътүлә Зөләйхане дәфен кылдылар* [2: 8];

*Йосыф бабай ханәсенә көнләрен берендә мөсафир бер хатын килде* [11: 40].

Бер-бер артлы башкарыла торган процессларны белдереп килгәндә, әлеге синтаксик берәмлекләр текстларда билгеле бер сөйләм агышын тудыру өчен хезмәт итәләр: *Бундан соңра кунаклара сыйлар, хөрмәтләр башлады. Әүвәлән, гадәтенчә, самавар мәйдана чыкды. Ашханәдә гайрәт вә хәрәкәт башланды* [1: 35]; *Мәзары кичдек. Мөфти хәзрәтләренең ханәсенә килдек. Хәзрәте ишан мөфти җәнабләрейлә күрешдек. Гайәт икрамла бәне истикъбаль итде. Хатырымы, хәлеме истифсар кылыб, тәгам софрасына бәне дәгъвәт итде* [4: 71].

Моннан тыш алар пейзаж картиналарында урын алалар. Әлеге очракта авторлар, тасвирлыкка ирешү өчен, гади хикәя җөмләләрнең җәенке төрләренә мөрәҗәгать итәләр: *Анчак якында кечүк бер су чырылдаб акыйур* [1: 37]; *Бу шәһәрнең биналары, урамлары, мәсҗедләренең күккә чыкган манаралары – җөмләсе мәхәббәтле күрелмәкдә иде* [10: 8].

Алга таба гади хикәя җөмләләр персонажларның портретларында кулланылалар: *Әбүзәр бәк бәһале ҫара сукна сюртук, шалвар кимеш* [1: 29]; *Кәндесе дә җәмәгатьләнмәмеш* [2: 11]; *Йөзендә улган тир борчаклары энҗеләргә охшаб тезелеб торадыр иде* [10: 18]; *Җөмләсенең бит-куллары яхшы юылган* [11: 83].

Шуның белән бергә язучылар әлеге синтаксик берәмлекләрне персонажларның рухи дөньясын һәм психологик халәтен ачып бирү чарасы буларак та файдаланалар: *Ике яшь бер-берсенә бакышыб бәхтияр улдылар* [1: 9]; *Яшь җаны Хисаметдин менлайа гашыйка улмыш* [1: 36]; *Хилафе фараз, Муса әфәнде зийадәчә мәхзүн улмамыш* [2: 34]; *Әхмәди бай илә Нигъмәтулла бик кайгыланмышлар* [2: 49].

XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында иҗат ителгән әсәрләрдә җыйнак һәм җәенке гади хикәя җөмләләр тагын персонажлар тарафыннан кайчандыр үткәндә гамәлгә ашырылган процессларны белдерү өчен җәлеп ителәләр: *Истанбулда укымыш* [1: 8]; *Менә бу мәктүбне мәкътүлә Зөләйха хәле хәйәтендә сезгә язмыш* [2: 11]; *Хәмелемне һәр кемдән сәтер кыла идем* [3: 26]; *Муса бундан унйидеунсигез сәнә мөкаддәм бер яшьлек кызыйла бер хатыныны аерыб йибәрмеш имеш* [11: 35–36].

Әлеге синтаксик берәмлекләргә хас стилистик үзенчәлекләр аларның публицистик чигенешләрдә фәлсәфи характердагы эчтәлек белән баетылып кулланылышында да чагылыш таба: *Төҗҗар тиҗарәт әфкярендә улган башҡа төҗҗар илә белешер. Игенче игенче илә катнашыр* [1: 29]; *Надан ана тәрбиясендә үскән бала файдалы кеше улмаз* [10: 66]; *Инсаның яшьлегендә алмыш тәрбиясе та каберенә кадәр берлекдә улыр, айырылмаз* [11: 94].

Әсәрләрнең фәнни стиль катламында һәм сәяхәтнамәләрдә алар авторлар тарафыннан укучыларга этнографик, конфессиональ һәм тарихи характердагы мәгълүматны җиткерү чарасы буларак җәлеп

ителәләр: *672 сәнә миладиядә Бикенде, Сәмәрканде, Кәше, Нәсәфе гарәбләр фәтех итделәр* [4: 4]; *Казан елгасының сул ягында вә Итилгә кушылган урында биек түбәгә бина иделмешдер* [10: 3]; *Кабан күле илә Болак Казан шәһәрене ике бүлемгә аермышдыр* [10: 3]; *Көллият әсәре Иран вә Һиндстанда күб мәртәбә табигъ иделмешдер* [10: 17].

Моннан тыш сәяхәтнамәләрдә гади хикәя җөмләләр авторлар тарафыннан аларның сәфәр вакытында очрашкан күренешләр тәэсире астында туган хис-кичерешләре турында сүз барганда да кулланылалар: *У сүзләр бәңа гаять агыр килде. Буныңла ихъялары зиярәт итмәкдән усандым* [4: 79]; *Бу қарт адәмең сүзләре зийадәсейлә хушымыза китде* [5: 39].

Әсәрләрдә мәгърифәтче язучылар аларны диалогларда яисә монологларда персонажларның сөйләмендә дә кулланалар: *Егермедән егерме өч манитка кадәр табамын* [1: 44]; *Мин Габденнәсыр әфәндене кичә иртә чәйгә дәгъвәт кылган идем* [2: 14]; *Менә без дә углымызны Казанга мәдрәсәгә укырга йибәрәмез* [3: 4].

Аерым очракларда диалогларда гади хикәя җөмләләрнең җыйнак һәм ким төрләре дә урын ала:

– *Шәһәрә бундан кач чакрым улыр әфәндем?*
– *Унике, унбиш улыр.*
– *Юл чук фәна, нәрәлесез әфәндем?...*
– *Нун карьясендәнмен* [1: 8];

– *Сез чәй эчдеңезме?*
– *Фәкать ике касә эчдем!*
– *Сез эчдеңезме?*
– *Бән, юк, эчмәдем!* [2: 37];

– *Телефонда кем?*
– *Бәндәңез (...) дер.*
– *Яныңда кем улса да берәр кемсәнә вармы?*
– *Мөсафирханә хадимендән башка һичкем юк.*
– *Чыксын!*
– *Чыкыб китде, хәлә ялңызым* [10: 76].

Авторлар персонажлар сөйләменә боерык җөмләләрне дә кертеп җибәрәләр: *«Тап кыз», – җаваб вирде Сибгатулла әфәнде* [1: 13].

Тикшерелгән әсәрләрдә әлеге төр гади җөмләләргә хас стилистик үзенчәлекләр аларның авторлар әңгәмәдәшенә караганда югарырак социаль статуска ия булган персонажларның сөйләмендә кулланылышында да чагылыш таба: *Соңра хезмәтчәләренә хитабән: «Әй, сез яшен кеби әйләнегез, кунаклара яхшы диккать идегез», – диде* [1: 34]; *Муса әфәнде «Бар, исемене белеб кил», – дидегендә, хадим чыгыб китде* [2: 10]; *«Ничек булса, кумәргә кирәк. Әйдә, казыңыз», – дийү имам хәзрәтләре әмер кылгач...* [3: 57].

Шулай ук боерык җөмләләр тәрбия дәрәҗәсе түбән булган һәм культуралы персонажларның сөйләмендә урын алып, дорфалык, тупаслык яисә әдәплелек маркерлары вазифаларын башкаралар: *«...Әйт*

*хәдисне гарәбчә!» – кычкырдылар шәкердләр* [1: 17]; *«Әйдә, чык. Судебный следовательгә әйтәләр», – дийү, Маһруйны бүлмәсендән чыгарыб, силахлы ике солдатның кулына тапшырды* [3: 24]; *Кызым, артык мөкаддәр улмаңыз!* [11: 114].

Аерым очракларда гади боерык җөмләләр каршы якка ихтирам белән әдәпле формада белдерелгән үтенечне җиткерү өчен кулланылалар: *Ләкин кунаклардан берсе: «Әйт инде, менла, үзләренә», – дидегенә күрә әйтде* [1: 18]; *Алла хаҗына... ярдәм кыл... Кара, ниндәй хәлгә дөшдем? Ярдәм вә хәляс кыл!* [1: 34]; *Зинһар, хәзрәт, үзең белгәнчә укыт!* [11: 8].

Охшаш стилистик вазифа аларга гашыйклар арасындагы диалогларда да йөкләнә: *Хәнифә ханым йарын таң илә багчада сарайдан егерме бишенче казык төбендә таш астында бер гаҗәиб шәй табарсыз. Алла ичүн бакың, риҗа идәрем* [1: 21].

Моннан тыш әлеге синтаксик берәмлекләр билгеле бер ситуацияләрдә Аллаһы Тәгаләгә ярдәм сорап мөрәҗәгать итү чарасы булып торалар: *Эшеңез начар, начар! Бик начар! Алла ярдәм кылсын!* [2: 21]; *Сиңа дөнья вә ахирәтдә сәгадәт насип итсен!* [10: 6]; *Йа Алла! Бу нә хәл! Йа Раббе! Хәлемә мәрхәмәт әйлә! Гакылыма куәт вир!* [11: 116].

XIX гасыр – XX гасыр башы татар поэзиясе әсәрләрендә сорау җөмләләргә хас стилистик үзенчәлекләр аларның риторик характердагы эчтәлек белән баетылып файдаланылуында чагылыш таба:

*Кайда китте цензурлык,*
*Коллык, тарлык, ким-хурлык?* [8: 53];

*Каты золым качан чумар?*
*Чын иркенлек качан чыгар?* [8: 323].

Әлеге стилистик үзенчәлек мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә дә чагылыш таба: *Мәктәбләрең, мәдрәсәләрең, мәсҗедләрең вакыфлары киләҗәкдә насыл улыр?* [4: 98]; *Буна нә чара? Кыйсмәт бөйләдерме? Яки тәрбиямез бөйлә улмышмы?...* [10: 37]; *Юкса безем галимләремез мәзкүр әсәрләре язан зәваты кәрамдан да бәләнд бер мәртәбәйә ирешделәрме?!...* [11: 25].

Гади тойгылы җөмләләргә килгәндә, мәгърифәтче язучылар әлеге синтаксик берәмлекләрне, нигездә, публицистик чигенешләрдә үз чорының татар җәмгыяте өчен хас булган тискәре күренешләре турында сүз алып барганда җәлеп итәләр: *Урада ун беңдән зиядә шәгерд иҗтиһадла дәрес укыр, йа Раббе! У кадәр милиунлар, у кадәр шәгердләрең газиз гомерләре биһудә шәйләрә сарыф улыныр, хараб улыр!* [4: 108]; *И хөрмәтле ислам байлары!... Вай, бай угыллары!... Вә кемләре дөнья вә ахирәт бәхетсезләрендән әйләмәз!...* [11: 66].

Шуның белән бергә гади тойгылы җөмләләр текстларда персонажларның психологик халәтен ачып бирүдә дә катнашалар: *Бунлар аналарына кушылганлар!... Мунчага су ташучы юк!... Сарыклар*

*көтүдә адашыб, бүленеб калганлар!... Базга куйган каймакга тычкан төшкән!...* [11: 106–107].

**Кушма җөмләләрнең стилистик кулланылышы.** XIX гасыр – XX гасыр башы татар поэзиясе әсәрләрендә кушма җөмләләргә хас стилистик үзенчәлекләр аларның риторик характердагы эчтәлек белән баетылып файдаланылуында чагылыш таба:

*Мәүламыз әмсалене итсен гадид,*
*Таки улсын бәхтяр гасры җәдид* [8: 33].

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә әлеге синтаксик берәмлекләргә хас стилистик үзенчәлекләр иң беренче чиратта аларның автор ремаркаларында кулланылышында чагылыш таба: *Туташның хәзердәге хиссиятене бәяна керешмейурыз, анҗак менланың күңеле фәррахлык илә тулмыш иде* [1: 38]; *Бу табылган мәктүбдә нә язылмыш дәйү тәфәккерә далыб беләсеңез килсә, хикәямездә, зиядә гад кылмайынча, табылган мәктүбне дә тәрҗемә кылыб язамыз* [2: 7]; *Хикәямезә Габделгафурның мәдхәле улдыгычүн, Габделгафурның кем вә ниндәләен адәм улдыгыны бәян идәмез* [3: 2]; *Имде бу хатынларны, хосусән яшь кызны, күп мәртәбә зикер итмәк лазем улдыгы ичүн «Сәлимә туташ» дийә йазамыз...* [10: 17]; *Ләкин «мөгаллимә ханым» тәгъбире илә хикәят итмәк йиңел улдыгындан, безләр хәзергә бунын мөбарәк исемләрене зикер итмейурмыз* [11: 91].

Гомумән алганда, тикшерелә торган әсәрләрдә кушма җөмләләр автор хикәяләвенең төп үзенчәлеген тәшкил итәләр: мәгърифәтче язучылар әлеге синтаксик берәмлекләрне фабула кору өчен файдаланалар. Аерым алганда, алар укучыларны әсәрләрдә тасвирланачак вакыйгаларга алып керәләр: *Нунлыларның бәгъзылары Хисаметдин менлайа рәгъбәт идәрләр иде, чүнкә ике сәнә зарфында язы язмак, хат танымак, гыйльме хисаб, гыйльме хәл балаларына үгрәтде* [1: 3]; *Җомга намазы вакыты йидмеш, Накәс мулла мәхәлләсе җәмәгате берәр-берәр мәсҗедә килейурлар* [3: 3].

Шуның белән бергә әлеге синтаксик берәмлекләр әсәрләрдә тасвирлана торган төп вакыйгаларга фон буларак барган процесслар турында сүз барганда кулланылалар: *Эчәрү керүдән мәнгы кылынсалар да, җәмәгать, нумер янындан таралмайынча, нә хәбәр улыр икән диб, тәфтишчеләрнең чыгуына мөнтәзыйр булыб торалар* [2: 4]; *Нигъмәтулла әфәнде өйдә юк, Муса әфәнде бик сусамыш, чәй эчейур һәм кулында гәзитә* [2: 9]; *Сатылачак нәрсәләр вә акча тәмам улгач... Мәмәт әфәнде янына тормайа күчде* [3: 51].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XIX гасыр – XX гасыр башы татар әдәби телендә җөмләләрнең стилистик кулланылыш үзенчәлекләре персонажларны тасвирлау, аларның рухи дөньяларын һәм психологик халәтләрен ачып бирү, пейзаж картиналарын тудыру, заман таләпләреннән чыгып, аерым социаль күренешләр һәм иҗтимагый институтларга бәя бирү, укучыларга этнографик, социаль-икътисади, конфессиональ, географик һәм тарихи характердагы мәгълүматны

җиткерү, фабула кору, хикәяләүне алып бару, текстларда билгеле бер сөйләм агышын тудыру, диалоглар һәм монологлар оештыру, аерым социаль даирәләрдә яисә иҗтимагый өлкәләрдә киң таралган тискәре күренешләрне тәнкыйтьләү кебек вазифаларны башкаруда чагылыш таба.

**Әдәбият**

1. *Акъегет М.* Хисаметдин менла: Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

2. *Бигиев З.* Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә. Роман. Казан: Тип. Г.М. Вечеслава, 1887. 77 б.

3. *Бигиев З.* Гөнаһе кәбаир. Роман. Казан: Тип. Г.М. Вечеслава, 1890. 72 б.

4. *Бигиев З.* Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр). Казан: Типолитогр. И.В. Ермолаевой, 1908. 108 б.

5. *Кәрими Ф.* Яурупа сәяхәтнамәсе. Оренбург: Тип. «Вакыт», 1902. 191 б.

6. Татар грамматикасы: өч томда / [проект җит. һәм авт. М.З. Зәкиев]. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. III. 536 б.

7. Татарская грамматика: в трех томах. Т. III. Синтаксис. Казань: ИЯЛИ АНТ, 1995. 576 с.

8. *Тукай Г.М.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт.: Н.Ш. Хисамов, З.З. Рәмиев. 407 б.

9. *Тукай Г.М.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: З.Р. Шәйхелисламов, Г.А. Хөснетдинова, Э.М. Галимҗанова, З.З. Рәмиев. 384 б.

10. *Фәхретдинов Р.* Сәлимә, яки Гыйффәт. Гафил бән Габдулла әсәре улап бер хикәятдер. Казан: Тип. Б.Л. Домбровского, 1899. 80 б.

11. *Фәхретдинов Р.* Әсма, яки Гамәл вә җәза. Оренбург: Тип. М.-Ф.Г. Каримова, 1903. 130 б.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Мирхаев Рифат Фирдинатович,***
*доктор филологических наук, доцент, ведущий научный сотрудник отдела общей лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*mirhaev77@mail.ru*